ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

15.11.2022
1507

КАРАР

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2015-2024 елларга Алабуга муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын раслау турында» 2014 елның 1 декрабендәге 1356 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Президентының «2018-2020 елларга коррупциягә каршы көрәш милли планы турында» 2018 елның 29 июнендәге 378 номерлы Указын, «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015-2020 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2015-2024 елларга Алабуга муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын раслау турында» 2014 елның 1 декабрендәге 1356 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программаның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2015-2025 елларга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру».

2. «2015-2025 елларга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын расларга (1 нче кушымта).

3. Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (Э.И. Садыйкова) әлеге максатларга җирле бюджетта каралган ассигнованиеләр чикләрендә программаны финанслауны тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карар рәсми төстә бастырып чыгарылырга тиеш.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 5DD9ADE894A62EB7F6C4DA0DBC7098E466BA
Владелец: Нургаянов Ленар Фаридович
Действителен с 03.12.2021 до 03.03.2023

Л.Ф. Нургаянов

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
“_____” ______ ____ел
карарына 1 нче кушымта
15.11.2022
1507

# «2015-2025 елларга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасы

**«2015 - 2025 елларга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасы**

**Программаның паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2015 – 2025 елларга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасы (алга таба-Программа) |
| Программаның заказчысы | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның төп эшләүчеләре | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның максаты | Алабуга муниципаль районында коррупциягә каршы тору системасын камилләштерү, коррупциягә каршы торучы шартлар тудыру, җәмгыятьтә коррупциягә карата тискәре мөнәсәбәт формалаштыру |
| Программаның бурычлары | 1. Коррупциягә каршы торучы корал һәм механизмнарны, шул исәптән, хокукый һәм оештыру өкәсендәгеләрне, камилләштерү;<br>2. Норматив хокукый актларда һәм акт проектларында, һәм норматив хокукый акт проектларында коррупциоген факторларны ачыклау һәм бетерү, коррупциягә каршы экспертиза уздыру юлы белән норматив хокукый актлар проектларында, норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру өчен шартлар тәэмин итү.<br>3. Мониторинг тикшеренүләре уздыру юлы белән коррупция халәтендә һәм коррупциягә каршы торуда процессларны һәм тенденцияләрне объектив бәяләүне тәэмин итү;.<br>4. Коррупциягә каршы укытуны активлаштыру һәм коррупциягә каршы пропаганда, коррупциягә каршы торуга кадрлар, матди, мәгълүмати һәм гражданлык җәмгыятенең башка ресурсларын җәлеп итү.<br>5. Муниципаль органнар эшчәнлегенең ачыклыгын, халык өчен үтемле булуын тәэмин итү, аларның |

| | |
|---|---|
| | гражданлык җәмгыяте белән элемтәсен ныгыту, җәмәгатьчелекнең коррупциягә каршы көрәш активлыгын стимуллаштыру.<br>6. Муниципаль милек куллануның нәтиҗәлелеген арттыру.<br>7. Эшкуарлыкка (бизнес) административ басымны эзлекле рәвештә киметү.<br>8. Мониторинг тикшеренүләре үткәрү юлы белән коррупциянең торышын бәяләү.<br>9. Хокук саклау органнары белән хезмәттәшлекнең нәтиҗәлелеген арттыру.<br>10. Көнкүреш коррупциясен минималь итү чараларын көчәйтү. |
| Гамәлгә ашыру вакыты | 2015-2025 еллар |
| Еллар һәм чыганаклар буенча бүленгән Программаны финанслау күләмнәре | Алабуга муниципаль районы бюджеты хисабына программаны финанслауның гомуми күләме 512,45 мең сум тәшкил итә: |

| Ел | Алабуга муниципаль районы бюджеты акчалары |
|---|---|
| 2015 | 73,0 |
| 2016 | 39,8 |
| 2017 | 49,75 |
| 2018 | 49,9 |
| 2019 | 50,0 |
| 2020 | 50,0 |
| 2021 | 0 |
| 2022 | 50,0 |
| 2023 | 50,0 |
| 2024 | 50,0 |
| 2025 | 50 |
| Барлыгы | 512,45 |

Искәрмә: финанслау күләме фараз характерында һәм, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төгәлләштерелергә тиеш.

| | |
|---|---|
| Программаның максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыруның көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре | Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча 2025 ел ахырына түбәндәге нәтиҗәләргә ирешү көтелә:<br>- коррупциягә каршы тору процессларында иҗтимагый оешмаларның активлыкны арттыру;<br>- җирле үзидарә органнарының кадрлар сәясәтенә эчке контроль һәм коррупциягә каршы механизмнарны кертү 100 проценка җитәчәк;<br>- проектларын эшләү чорында коррупциягә каршы экспертизага дучар ителгән закон һәм башка норматив хокукый актларның өлеше 100 процентка җитәчәк;<br>-квалификация күтәрүне узган дәүләт граждан (муниципаль) хезмәткәрләре өлеше ел саен кимендә 33 процентка җитәчәк;<br>- гражданнарның дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү сыйфатыннан канәгать булу дәрәҗәсе 90 процентган да ким булмаячак;<br>- коррупциягә каршы үткәрелгән чаралардагы муниципаль хезмәткәрләрнең өлеше, ким дигәндә, 70 процентка җитәчәк;<br>- тору урыны буенча, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә дә, «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр алу мөмкинлеге булган гражданнар өлеше 90 процентган да ким булмаска тиеш; -гражданнарның җирле үзидарә органнарына ышанычын ныгыту;<br>- җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаи затлар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт белән бәйле тыюларны һәм чикләүләрне үтәү;<br>- гражданнарның дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына ышанычын арттыру;<br>-Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының рәсми сайтларын урнаштыруга һәм аларның бүлекләрен тутыруга Бердәм таләпләрне раслау турында» 2013 елның 4 апрелендәге 225 номерлы карары һәм законнар белән билгеләнгән таләпләр нигезендә, коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникацион челтәрендә җирле үзидарә органнарының рәсми сайтларындагы бүлекләрне тулыландыру 90 процентган да ким булмаячак;<br>- гражданнар һәм оешмалар өчен җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең ачыклыгы һәм уңайлыгы, аларның гражданлык җәмгыяте белән бәйләнешен |

| | |
|---|---|
| | ныгыту;<br>-муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуларны оештыру һәм уздыру өлкәсендәге эшчәнлекнең үтә күренмәлелеген тәэмин иткән Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнары өлеше кимендә 100 процент тәшкил итәчәк. |
| | |

## I. Программаны гамәлгә ашыру өлкәсенең гомуми характеристикасы. Төп проблемалар һәм аларны хәл итү юллары

Коррупция дәүләт һәм җәмгыятьнең социаль-икътисадый үсешенә тискәре йогынты ясый, конкурентлыкка сәләтле икътисад формалашуга киртә булып тора, халыкның тормыш-көнкүреш үсешен, алга киткән гражданлык җәмгыяте барлыкка килүне тоткарлый. Шуңа бәйле рәвештә соңгы елларда Татарстан Республикасында һәм тулаем район буенча Коррупциягә каршы көрәш чараларының активлашуы, республика, ведомство һәм муниципаль дәрәҗәләрдә законнар чыгару һәм хокук куллану эшчәлегенең камилләшүе белән характерлана.

Әлеге программаларны тормышка ашыру вакытында районда җирле үзидарә органнарында коррупциягә каршы эшчәнлекне координацияләү системасы төзелде. Коррупциягә каршы тору буенча комиссия (совет) төзелде; коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау өчен җаваплы затлар билгеләнде;

дәүләт (муниципаль) хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссияләр төзелде. Коррупциягә каршы әүвәлге программа чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәсе буларак, коррупциягә каршы эшчәнлектә гражданнар җәмгыяте институтларының роле артуы белән билгеләнә. Шулай итеп, җәмәгатьчелек вәкилләре халык хакимияте органнары каршындагы коррупциягә каршы комиссияләр, дәүләт (муниципаль) хезмәткәрләренең эш урынында үз-үзен тотышына карата таләпләрне үтәү буенча комиссияләр, конкурс һәм аттестация комиссияләре составына кертелделәр. Яшьләр иҗтимагый оешмалары һәм республика массакүләм мәгълүмат чаралары коррупциягә каршы эшчәнлекнең актив катнашучылары булдылар, һәм, шуның нәтиҗәсе буларак, җәмгыятьтә коррупцион тәртипкә карата түземсезлек формалаша.

## II. Программаның максаты һәм төп бурычлары.Программаның көтелгән соңгы нәтиҗәләрен тасвирлау, аны тормышка ашыруның вакыты һәм этаплары

Коррупция сәбәпләрен ачыклау һәм бетерү, аның чагылышына ярдәм итүче шартларга каршы тору, җәмгыятьтә коррупциягә карата тискәре мөнәсәбәт

формалаштыру – Программаның максатлары булып тора. Программаның максатларына ирешү өчен түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү таләп ителә:
коррупциягә каршы торучы корал һәм механизмнарны, шул исәптән, хокукый һәм оештыру өлкәсендә дә, камилләштерү;
норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү оештыруны камилләштерү;
коррупциягә каршы мониторинг үткәрү;
коррупциягә каршы укытуны һәм коррупциягә каршы пропаганданы активлаштыру, коррупциягә каршы гражданнар җәмгыятенең кадрлар, матди, мәгълүмати һәм башка ресурсларын җәлеп итү;
муниципаль органнар эшчәнлегенең ачыклыгын, халык өчен үтемле булуын тәэмин итү, аларның гражданлык җәмгыяте белән элемтәсен ныгыту, җәмәгатьчелекнең коррупциягә каршы көрәш активлыгын стимуллаштыру;
дәүләт (муниципаль) ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне оештыру һәм уздыру өлкәсендәге эшчәнлекне камилләштерү;
эшкуарлыкка (бизнес-структуралар) административ басымны эзлекле рәвештә киметү;
хокук саклау органнары белән хезмәттәшлекнең нәтиҗәлелеген арттыру; көнкүреш коррупциясен минималь итү чараларын көчәйтү;
дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләрнең коррупциягә каршы тәртибен стимуллаштыру**.**

Программаны тормышка ашыру срогы - 2015-2025 еллар.

Программаны тормышка ашыру этаплары аерылып тормый. Программаның төп максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары, шулай ук, Программада каралган чараларны финанслау күләме кушымтада күрсәтелгән.

## III. Программаны ресурслар белән тэмин ителешен дәлилләү

Программаны финанслауның гомуми күләме 2015 - 2025 елларда Алабуга муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән 512,45 мең сум тәшкил итә.

| Ел | Алабуга муниципаль районы бюджеты акчалары |
|---|---|
| 2015 | 73,0 |
| 2016 | 39,8 |
| 2017 | 49,75 |
| 2018 | 49,9 |
| 2019 | 50,0 |
| 2020 | 50,0 |
| 2021 | 0,0 |
| 2022 | 50,0 |

| | |
|---|---|
| 2023 | 50,0 |
| 2024 | 50,0 |
| 2025 | 50.0 |
| Барлыгы | 512,45 |

Программаны финанслау күләме фаразланган характерда һәм район бюджетының мөмкилекләреннән чыгып, анда ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш. Моннан тыш, Программа чараларын тормышка ашыру өчен чараларны башкаручыларның төп эшчәнлеген финанслауга бүлеп бирелгән акчаларны файдалану күздә тотыла.

## IV. Программаны тормышка ашыру механизмы

Программаның үтәлешен планлаштыруны, үзара хезмәттәшлекне, координацияне һәм гомуми контрольне Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты гамәлгә ашыра, ул ел саен программа чараларына максатчан күрсәткечләрне һәм чыгымнарны, Программаны гамәлгә ашыру механизмын һәм башкаручылар составын төгәлләштерә, Программаның үтәлеше өчен җаваплы кешеләрдән аның үтәлеше турында белешмәләр соратып ала.

Программаны гамәлгә ашыру, аларны үтәү срокларын, бюджет ассигнованиеләрен күрсәтеп, чаралар исемлеге булган еллык план нигезендә гамәлгә ашырыла.

Чараларны финанслау аларны гамәлгә ашыру өчен җаваплы һәм Программаны башкаручы булган җирле үзидарә органнары, муниципаль учреждениеләр аша гамәлгә ашырыла.

Тиешле чараларны гамәлгә ашыру өчен җаваплы Программаларны үтәүчеләр Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетына квартал саен хисап чорыннан соң килүче айның 25 числосына кадәр чараларның үтәлеше һәм шул чараларны үткәрүчеләргә бүленеп бирелгән акча чыгымнары хакында үсешле нәтиҗәләргә, һәм, тулаем алганда, хисап елы өчен тотылган акча турында мәгълүматларны тапшыралар.

Программаны гамәлгә ашыру һәм аның нәтиҗәлелеген бәяләү турында еллык хисап (алга таба - еллык хисап) Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты, хисабыннан соң килүче елның 1 мартына кадәр башкаручылар белән берлектә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә тапшыра.

Еллык хисапта түбәндәгеләр керә:

- хисап чорында ирешелгән конкрет нәтиҗәләр;

- билгеләнгән вакытта башкарылган һәм үтәлмәгән (сәбәпләрен күрсәтеп) чаралар исемлеге;

- Программаны гамәлгә ашыру барышына йогынты ясаган факторларны анализлау;

- чаралар башкаруга бюджет ассигнованиеләреннән һәм башка акчалардан файдалану турындагы күрсәткечләр һәм башка мәгълүматләр.

Программага үзгәрешләр кертү Программаның чараларын җаваплы башкаручы белән килештереп йә билгеләнгән таләпләр нигезендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте йөкләмәләрен үтәп гамәлгә ашырыла.

## V. Программаның социаль-икътисади нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаның тормышка ашу нәтиҗәлелеген бәяләү, Кушымтада китерелгән, 2025 елга программа үтәлеше нәтиҗәләрен бәяләү индикаторы күрсәткечләренә ирешүне исәпкә алып үткәрелә.

Программа чараларын үтәү түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:

- коррупциягә каршы көрәш инструментларын һәм механизмнарын, шул исәптән хокукый һәм оештыру механизмнарын камилләштерүгә;
- Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнарының коррупциягә каршы сәясәтен координацияләү нәтиҗәлелеген арттыруга;
- мониторинг тикшеренүләр уздыру, мондый каршылыкның инновацион технологияләрен эзләү һәм кертү юлы белән коррупциягә каршы тору һәм коррупция халәтендәге процессларга һәм тенденцияләргә объектив бәя бирүне тәэмин итүгә;
- коррупциягә каршы укытуны һәм коррупциягә каршы пропаганданы активлаштырырга, гражданлык җәмгыятенең кадрлар, матди, мәгълүмат һәм башка ресурсларын коррупциягә каршы көрәшкә җәлеп итүгә;
- дәүләт һәм муниципаль мөлкәттән файдалануның нәтиҗәлелеген арттырырга; - эшкуарлык (бизнес) өчен административ басымны киметүгә;
- муниципаль хезмәткәрләрнең коррупциягә каршы үз-үзләрен тотышын стимуллаштыруга.

Моннан тыш, программа чараларын комплексы үтәү районда коррупциягә каршы институтларны үстерүгә һәм ныгытуга ярдәм итәчәк. Коррупциягә каршы белем камилләшәчәк. Коррупциягә каршы тематика буенча квалификация күтәрү курсларын узган муниципаль хезмәткәрләр саны артачак.

Программаның социаль нәтиҗәсе гражданнарның үз конституциячел хокукларын һәм ирекләрен тулырак гамәлгә ашыруы белән бәяләнә.

Программаның үзенчәлеген исәпкә алып, туры икътисадый нәтиҗәне билгеләү мөмкин түгел, чөнки программа чаралары гади статистик үлчәүләргә бирелми һәм бәяләр бәяләвендә чагыла алмый. Шул ук вакытта Программа чараларын гамәлгә ашыруның турыдан-туры икътисадый нәтиҗәсе Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының җәлеп итүчән имиджын формалаштыру, шул исәптән инвестицион җәлеп итүчәнлек, эшкуарлык активлыгын күтәрү, районда җирле үзидарә органнарында коррупция чагылышларына бәйле бюджет югалтуларын киметү нәтиҗәсендә күзәтелергә мөмкин.

Программада эшчәнлекнең нәтиҗәләрен характерлаучы индикаторлар һәм

күрсәткечләр системасы кулланыла. Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү аны гамәлгә ашыруның бөтен чорында 2025 елга кадәр Программаны үтәү нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары буенча күрсәткечләргә ирешүне исәпкә алып уздырыла.

Кушымта

**Муниципаль программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары «2015-2025 елларда Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне тормышка ашыру» һәм программа чаралары буенча финанслау**

| Төп чаралар исеме | Башкару чылар | Төп чараларны үтәү вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторлар күрсәткечләре | | | | | | | | | | | | Финанслау (АМР бюджеты акчалары исәбеннән), мең сум | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2013 ел (база елы) | 2015 ел | 2015 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| **1** | **2** | **3** | **4** | **5** | **6** | **7** | **8** | **9** | **10** | **11** | **12** | **13** | **14** | **15** | **16** | **17** | **18** | **19** | **20** | **21** | **22** | **23** | **24** | **25** | **26** | **27** |
| Максат: коррупциянең сәбәпләрен ачыклау һәм бетерү, аның күренешләренә каршы тору, җәмгыятьтә коррупциягә карата түземсез мөнәсәбәт формалаштыру | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1 бурыч. Коррупциягә каршы тору инструментларын һәм механизмнарын, шул исәптән хокукый һәм оештыру механизмнарын камилләштерү | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.1. Законнар нигезендә һәм коррупциягә каршы көрәш турында муниципаль норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү һәм коррупциягә каршы көрәш практикасын гомумиләштерү нигезендә норматив хокукый актлар әзерләү | АМР хокук палатасы (килешү буенча) | 2015-2025 еллар | Эчке контроль һәм коррупциягә каршы механизм кертkән АМР җирле үзидарә органнары өлеше, процентларда | 94 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - | - | - | - | - | - | | | - |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.2. Коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча җирле үзидарә органнары бүлекчәләренең (коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы кадрлар хезмәтләренең вазыйфаи затларының) эшчәнлеге | АМР Советының кадрлар хезмәте (килешү буенча) | 2015 - 2025 еллар | | | | | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | | - | | | - |
| Россия Федерациясе Президентының 2009 елның 21 сентябрендәге 1065 номерлы һәм Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 1 ноябрендәге ПУ-711 номерлы Указлары нигезендә әлеге юнәлеш буенча кадрларның тотрыклылыгы принципын үтәү. | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | - | | | | - |
| 1.2.1. Муниципаль хезмәт | АМР Советын | 2015 - 2025 | | | | | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - | - | | | - |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| турында законнар таләпләрен үтәп, коррупциягә каршы көрәш турында керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерүне үткәрү хезмәткәрләрнең, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының мөлкәти характердагы йөкләмәләре: муниципаль хезмәткәрләр муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар. Тикшерү барышында ачыкланган хокук бозулар турында ТР прокуратурасы органнарына хәбәр итү | ың кадрлар хезмәте (килешү буенча) | еллар | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.2. Муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәт турындагы | АМР Советының кадрлар хезм | 2015 - 2025 еллар | | | | | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - | - | | | - |



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| законнарда каралган чикләүләрне һәм тыюларны, шул исәптән федераль салым хезмәтенең ЕГРЮЛ һәм ЕГРИП мәгълүмат базаларын кулланып, эшмәкәрлек эшчәнлегендә катнашу предметын (елына бер тапкырдан да ким булмаган)үтәүләрен тикшерү | эте (килешү буенча), АМР мәнфәгатьләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм конфликтын жайга салу комиссиясе (килешү буенча) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.2.3. Яллаучы (эш бирүче) вәкиле тарафыннан билгеләнгән тәртиптә муниципаль хезмәткәрне коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларынд | АМР Советының кадрлар хезмәте (килешү буенча) | 2015 - 2025 еллар | | | | | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - | - | | | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| а мөрәҗәгать итү фактлары турында мәгълүматларны тикшерү | ҖҮО (килешү буенча), | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.2.4. Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан функцияләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган коррупциячел хәвеф-хәтәрләрне системалы рәвештә бәяләүне үткәрү һәм коррупция куркынычлары белән бәйле муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегенә үзгәрешләр кертү | АМР ҖҮО ( килешү буенча), хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Комиссия (килешү буенча) | ел саен | | | | | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - | - | | | - |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.2.5.<br>1.2.6. Махсус программа белән тәэмин итү нигезендә эшләнгән компьютер программаларын коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча бүлекчәләр эшчәнлегендә тиешле исемлекләргә кертелгән затлар һәм әлеге вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, күчемсез мөлкәт (шул исәптән чит илләрдә), транспорт чаралары, счетлар, кредитлар, кыйммәтле кәгазьләр турында мәгълүматлар базасын кулланып бирелә торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы | АМР ҖҮО (килешү буенча), АМР Советының кадрлар хезмәте (килешү буенча) | Кертеп җибәрү - 2015 ел. Куллану - 2015 - 2024 еллар. | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| белешмәләргә мониторинг һәм автоматлаштырылган анализ ясау; гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм аларны граждан-хокукый шартнамәсе (граждан-хокукый шартнамәләр) шартларында яисә әлеге оешмада хезмәт шартнамәсе шартларында эш башкаруга (хезмәт күрсәтүгә) вазыйфаларны оештыруда, әгәр әлеге оешма белән муниципаль (административ) идарә итүнең аерым функцияләре муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи (хезмәт) бурычларына керсә, бу оешма тарафыннан хезмәт шартнамәсе шартларында вазыйфа (хезмәт | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| күрсәтүләр) оештыруга кертү һәм куллану; | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.2.6. Муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның шәхси эшләрен алып баруга кагылышлы өлешендә кадрлар эшенең нәтиҗәлелеген арттыру, шул исәптән күрсәтелгән вазифаларга билгеләгәндә һәм мондый хезмәткә | АМР Советының кадрлар хезмәте (килешү буенча) | 2018 - 2025 еллар ярты елга бер тапкыр. | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| кергәндә бирелә торган анкетадагы белешмәләрне актуальләштерүне контрольдә тоту буенча чаралар күрү, мәнфәгатьләр каршылыгын ачыклау максатларында | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.3. Алабуга муниципаль районының коррупциягә каршы көрәш комиссиясенең ачыклыгын һәм нәтиҗәле эшчәнлеген тәэмин итү, шул исәптән иҗтимагый советлар вәкилләрен һәм граждан җәмгыятенең башка институтларын эшчәнлеккә җәлеп итү юлы белән | АМР коррупциягә каршы көрәш буенча эшне координацияләү комиссиясе (килешү буенча) | 2015 - 2025 еллар | | | | | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - | - | | | - |
| 1.4. Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм федераль һәм республика законнарында | АМР мәнфәгатьләренең хезмәт тәртибен | 2015 - 2025 еллар | | | | | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - | - | | | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| билгеләнгән таләпләр нигезендә мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиянең нәтиҗәле эшләвен тәэмин итү | ә таләпләрне үтәү һәм конфликтын җайга салу комиссиясе (килешү буенча), АМР Советының кадрлар хезмәте (килешү буенча) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.5. Закон нигезендә Алабуга муниципаль районы сайтында муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр | АМР Советының кадрлар хезмәте (килешү буенча) | 2015-2025 еллар | | | | | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - | - | | | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| урнаштыру | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.6. « Халык инвентаризациясе» акциясен үткәрү (су һәм урман законнары буенча), халыкны урманнардан һәм су саклау зоналарыннан законсыз файдалану һәм төзү белән бәйле хокук бозуларны ачыклау максатыннан үткәрелә. Ачыкланган хокук бозуларны булдырмау һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү өчен чаралар күрү | АМР Башкарма комитеты АМР Җир һәм мөлкәт палатасы (килешү буенча) | 2016 - 2025 еллар | Су һәм урман законнары өлкәсендә ачыкланган хокук бозулар саны | - | - | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 1.7. Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан мәнфәгатьләр конфликтын булдырмауга һәм җайга салуга кагылышлы коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе | АМР Советының кадрлар хезмәте (килешү буенча), - АМР мәнфәгатьлә | 2018 - 2025 еллар, квартал саен. | Үткәрелгән анализлар/муниципаль хезмәткәрләрнең гомуми санынан мәнфәгатьләр конфл | - | - | - | - | 5 | 5 | 10 | 10 | 10 | 10 | 10 | 10 | - | - | - | - | - | - | - | - | | | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| законнары таләпләренең үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру | рененң хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм конфликтын җайга салу комиссиясе (килешү буенча) | | иктын булдырмау һәм җайга салу турындагы таләпләрнең үтәлешен тикшерү. Мәнфәгатьләр конфликты белән бәйле хокук бозган муниципаль хезмәткәрләр саныннан мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән өчен дисци | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | плинар җаваплылыкка тартылучылар саны | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.8. Муниципаль вазифаларны һәм муниципаль хезмәт вазфаларын биләүче затларның шәхси эшләрен алып баруга, шул исәптән күрсәтелгән вазифаларга билгеләп куйганда тапшырыла торган анкеталардагы белешмәләрне актуальләштерүгә һәм мондый хезмәткә кергәндә, аларның туганнары һәм үзлекләре (ирләренең яисә хатыннарының ирләре, бертуганнарының һәм хатыннарының сеңелләре турында) | АМР Советының кадрлар хезмәте (килешү буенча), - АМР мәнфәгатьләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм конфликтын җайга салу комиссиясе | Даими | Эчке контроль һәм коррупциягә каршы механизмны кадрлар сәясәтенә керткән муниципаль районның җирле үзидарә органнары өлеше - процентларда | - | - | - | - | - | - | - | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| турында, мәнфәгатьләрнең мөмкин булган конфликтын ачыклау максатларында кадрлар эшен гамәлгә ашыру | (килешү буенча) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.9. Татарстан Республикасында муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашуына мониторинг үткәрү | АМР Советының кадрлар хезмәте (килешү буенча), - АМР мәнфәгатьләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм конфликтын җайга салу комиссиясе | даими | Ведомство карамагындагы оешмаларның гомуми саныннан тикшерелгән өлеше - процентларда | - | - | - | - | - | - | - | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | (килешү буенча) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.10. «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13.3 статьясындагы нигезләмәләрендә каралган чараларны, шул исәптән ҖҮО ведомствосындагы оешмаларның мәнфәгатьләре конфликтын ачыклау, булдырмау һәм җайга салу буенча, үтәүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру | Муниципаль районның Башкарма комитеты,. | 2021-2025 еллар | Ведомство карамагындагы оешмаларның гомуми санынннан тикшерелгән өлеше - процентларда | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 2 бурыч. Норматив хокукый актларда һәм норматив хокукый актлар проектларында коррупциячел факторларны ачыклау һәм бетерү, норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен шартлар тәэмин итү | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 2.1. Норматив хокукый актларга һәм аларның проектларына коррупциягә каршы экспертизаны нәтиҗәле уздыруны оештыру | АМР хокук палатасы (килешү буенча) | 2015-2025 еллар | Коррупциягә каршы экспертизага дучар ителгән норматив хокук | 95 | 96 | 96 | 97 | 97 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - | - | - | - | - | | | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| буенча гамәли чаралар кабул итү, аны үткәрү нәтиҗәләрен ел саен гомумиләштерү | | | ый актларның аларның проектларын эшләү стадиясендә өлеше - процент | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 2.2. Норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен кирәкле шартлар тудыру | АМР хокук палатасы (килешү буенча) | 2015 – 2025 еллар | | | | | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | | - | | | - |
| 3 бурыч Мониторинг тикшеренүләре үткәрү юлы белән коррупциянең торышын бәяләү | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 3.1. АМР территориясендә коррупциягә каршы чараларны гамәлгә ашыруга мониторинг үткәрү һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү | АМР коррупциягә каршы көрәш эшен координацияләү комиссиясе (килешү буенча) | 2015 - 2025 еллар | Социологик сораштырулар оештыру буенча дәүләт йөкләмәсен үтәүнең тулылыгы - процентларда | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - | - | - | - | - | - | | | - |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.2. Максатчан төркемнәр арасында коррупцион факторларны һәм коррупциягә каршы чараларны гамәлгә ашыру буенча тармак тикшеренүләре үткәрү. Коррупциягә каршы тору кысаларында превентив чаралар эшләү өчен алынган нәтиҗәләрне куллану | АМР коррупциягә каршы көрәш эшен координацияләү комиссиясе (килешү буенча) | 2015 - 2024 еллар | | | | | | | | | | | | 100 | 100 | - | - | - | - | - | - | | - | | | - |
| 3.3. Мониторинг үткәрү: гражданнар җәмгыяте институтларының коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыруга җәлеп ителүе; массакүләм мәгълүмат чаралары материаллары коррупция темасына | АМР Советының ҖҮО белән эшләү бүлеге (килешү буенча), Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләл | 2015 - 2025 еллар | | | | | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | | - | | | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | әре буенча башлык ярдәмчесе (килешү буенча) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 3.4. АМРда коррупция торышын мониторинглау максатларында халыкның төрле төркемнәреннән социологик сораштырулар үткәрү | АМР Советы (килешү буенча) | 2015-2025 еллар, елга кимендә 1 тапкыр | Үткәрелгән социологик сорашып белешүләр саны | | | | | | | | 1 | 1 | 1 | 1 | | 73,0 | 39,8 | 49,75 | 49,9 | 50,0 | 50,0 | 0,0 | 50,0 | 50,0 | 50,0 | 50,0 |
| 4 бурыч. Коррупциягә каршы укытуны һәм коррупциягә каршы пропагандалауны активлаштыру, кадрлар, матди, мәгълүмати һәм башка ресурсларны коррупциягә каршы көрәшкә җәлеп итү | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4.1. Коррупциягә каршы торуда катнашучы аерым категория хезмәткәрләрнең, шулай ук җәмәгатьчелек вәкилләренең һәм башка затларның квалификациясен күтәрүгә юнәлдерелгән кыска сроклы махсуслаштырылган семинарлар оештыру һәм үткәрү | АМР коррупциягә каршы көрәш буенча эшне координацияләү комиссиясе (килешү буенча), АМР мәнфәгатьләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм конфликтын җайга салу комиссиясе | 2015 - 2025 еллар | Муниципаль хезмәткәрләрнең аерым категорияләренең, шулай ук җәмәгатьчелек вәкилләренең һәм коррупциягә каршы көрәштә катнашучы башка затларның квалификациясен күтәрүгә юнәлдерелгән чаралар саны | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | - | - | - | - | - | - | - | - | | | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | (килешү буенча), АМР Советының кадрлар хезмәте (килешү буенча) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 4.1.1. Коррупциягә каршы торуда катнашучы муниципаль хезмәткәрләрнең ел саен махсуслаштырылган квалификацияләрен күтәрү курсларын узу | АМР Советының кадрлар хезмәте (килешү буенча) | 2018 - 2025 елларда, ярты елга бер тапкыр | Вазыйфаи бурычларына коррупциягә каршы тору буенча махсуслаштырылган квалификация күтәрүче (кименндә 50%) хезмәткәрләр саны. | - | - | - | - | 50 | 70 | 90 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - | - | - | - | - | - | | | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
